МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 174/о

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«17» 10 2016

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында алар буенча вазифаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, аларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында

2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” № 79-ФЗ Федераль законның 22 статьясының 3 өлешенә туры китереп, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 12 августындагы “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының штат расписаниесен раслау турында” № 135/о боерыгы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында алар буенча вазифаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, аларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага шушы боерыкны Министрлыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 08 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында алар буенча вазифаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне файдалануга бәйле булган, аларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында”гы № 148/о боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2016 елның
“17” 10 № 174/0
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында алар буенча вазифаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне файдалануга бәйле булган, аларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге

Эшләр белән идарә итүче;
дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы;
бюджет үтәлеше, исәпкә алу һәм хисапнамә бүлеге башлыгы;
юридик бүлек башлыгы;
мобиль әзерлек, гражданлык оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм яшеренлелек режимы секторы җитәкчесе;
мобиль әзерлек, гражданлык оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм яшеренлелек режимы секторының әйдәп баручы киңәшчесе;
икътисади анализ һәм дәүләт программаларын рәвешкә китерү идарәсе башлыгы;
җыелма-аналитика бүлеге башлыгы;
мәгълүматлаштыру секторы җитәкчесе;
төзелеш комплексын үстерү идарәсе башлыгы;
төзелеш технологияләре бүлеге башлыгы;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең шәһәр төзелеше сәясәте бүлеге башлыгы;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең шәһәр төзелеше сәясәте бүлеге башлыгы урынбасары;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзү бүлеге башлыгы;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең архитектура һәм проектлау бүлеге башлыгы;
шәһәр төзелеше эшчәнлеген контрольдә тоту бүлеге башлыгы;
эксплуатацияләү һәм ТКХ программаларын үтәү идарәсе башлыгы;
эксплуатацияләү һәм ТКХ программаларын үтәү идарәсенең ТКХ объектларын эксплуатацияләүне мониторинглау бүлеге башлыгы;
эксплуатацияләү һәм ТКХ программаларын үтәү идарәсенең капиталь ремонт программаларын үтәү бүлеге башлыгы;
ТКХ үзгәртеп кору һәм модернизацияләү бүлеге башлыгы.